ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2021 елның «22» гыйнвареннән № 31

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен спорт инструкторларын һәм спортчыларны бүләкләү турында Нигезләмәне раслау хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларны, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спорт инструкторларын һәм спортчыларны бүләкләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1258 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 22 октябрендәге 946 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп куелган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен спорт инструкторларын һәм спортчыларны бүләкләү Тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә ел саен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында» Килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 октябрендәге 250 нче номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында Нигезләмәне раслау хакында”гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче в.б. Л.К. Исхакова

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «22» гыйнварендәге
№ 31 карары белән расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен спорт инструкторларын һәм спортчыларны бүләкләү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – район Башкарма комитеты) башкарган "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларга, адаптив физик культура буенча тренерларга (шул исәптән өлкәннәр өчен), шулай ук спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен спорт инструкторларына һәм спортчыларга акчалата түләүләр бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

Оешманың Координаторлары булып - Башкарма комитетларның функциональ органы-Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (алга таба-Бүлек) тора.

2. Тренерларга, тренер-укытучыларга, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләкләү Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына әлеге Тәртипнең 1 пунктында һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган акчалар хисабына башкарыла.

3. Акчалата түләү күләме тәрбияләнүченең спорт нәтиҗәсе нигезендә билгеләнә һәм ярышларны оештыручы билгели торган судьялар комиссиясе тарафыннан бәяләнә, спортчы күрсәткән нәтиҗәдән соң, бер календарь ел дәвамында ярышлар протоколын төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

4. Югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен, ярышларда алган урын буенча, һәр дәрәҗәдәге ярышларда, медаль комплектлары уйнатылган очракта, бер яхшы нәтиҗә өчен (спортчының сигез ярышыннан да артык түгел), программаның шәхси һәм команда төрләрендә спортчы күрсәткән югары нәтиҗәләр өчен түләү процент суммасыннан бирелә. Төп тренер белән бер үк вакытта эшләү шартларында өстәмә рәвештә югары квалификацияле спортчыны әзерләүгә җәлеп ителә торган тренерлар, тадаптив физкультура буенча тренер-укытучылар өчен (шул исәптән өлкәннәр өчен), спортчыларның тренировка эшенең бер атналык режимына пропорциональ рәвештә туры килгән шартларда, билгеләнгән урын буенча югары квалификацияле спортчыларны әзерләү өчен хезмәт хакы нормативлары төп тренер белән бер

үк шартларда билгеләнә.

5. Рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында ирешкән нәтиҗәләр өчен спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның хезмәт хакы нормативы, билгеләнгән урын буенча, ярышлар беркетмәсенең бер календарь ел дәвамында спортчылар-инструкторлар, спортчылар күрсәткән нәтиҗәдән чыгып билгеләнә.

6. Спортчы-инструктор, спортчыга түләү нормативы, рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында яулаган нәтиҗәләр өчен, билгеләнгән урын буенча, шәхси һәм команда төрләрендә, әгәр медаль комплектлары уйнатыла икән, программаның шәхси һәм команда төрләрендә күрсәтелгән һәр дәрәҗәдәге ярышларда (сигез ярыштан да артык түгел) иң яхшы нәтиҗә өчен процент суммасыннан чыгып билгеләнә.

7. Нәтиҗә өчен акчалата түләү тренерларга, адаптив физик культура буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәр өчен), әгәр дә әлеге программа буенча катнашучылар саны (пар, төркемнәр, экипажлар, спортчылар командалары) түбәндәге күләмдә булганда билгеләнә:

6 дан да ким булмаган спорт төре (инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар шөгыльләнә торган спорт төрләреннән тыш);

5 тән дә ким булмаган (инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар шөгыльләнә торган спорт төрләре өчен).

8. Югары квалификацияле спортчыларны әзерләгән өчен тренерларга, тренерларга, адаптив физик культура буенча тренерларга (шул исәптән өлкәннәр өчен) акчалата түләүләр спортчы белән ярышларда нәтиҗә алганчыга кадәр кимендә ике ел эшләү шарты белән билгеләнә.

Тренерлар,
адаптив физик культура буенча (шул исәптән өлкәннәр белән эшләү) тренер-укытучылар хезмәтенә бер шөгыльләнүче исәбенә ярышларда алган урын буенчаюгары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен түләү нормативлары
(процентларда)

| Ярышларның дәрәҗәсе | Алынган урын | Хезмәткә түләү нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Спортның олимпия төрләре, олимпия дисциплиналары | | Спортның олимпия булмаган төрләре, олимпия булмаган дисциплиналары | |
| | | шәхси | команда | шәхси | команда |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Олимпия уеннары | 1 | 500,0 | 500,0 | - | - |
| | 2 | 375,0 | 375,0 | - | - |
| | 3 | 250,0 | 250,0 | - | - |
| | 4 | 200,0 | 200,0 | - | - |
| | 5 | 188,0 | 188,0 | - | - |
| | 6 | 125,0 | 125,0 | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | катнашу | 63,0 | 63,0 | - | - |
| Дөнья Чемпионаты | 1 | 75,0 | 75,0 | 52,5 | 37,5 |
| | 2 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |
| | 3 | 65,0 | 65,0 | 47,5 | 32,5 |
| | 4 | 60,0 | 60,0 | 45,0 | 30,0 |
| | 5 | 55,0 | 55,0 | 42,5 | 27,5 |
| | 6 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| Дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |
| | 2 | 65,0 | 65,0 | 45,0 | 32,5 |
| | 3 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 4 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 5 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 6 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 7 - 12 | 15,0 | 15,0 | 12,5 | 7,5 |
| Ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 2 | 17,5 | 17,5 | 8,8 | 8,8 |
| | 3 | 15,0 | 15,0 | 2,5 | 7,5 |
| Европа Кубогы | 1 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 2 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 3 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 4 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 5 - 10 | 22,5 | 22,5 | 20,0 | 11,3 |
| Бөтендөнья универсиадасы | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Россия Чемпионатя | 1 | 50,0 | 17,5 | 35,0 | 8,8 |
| | 2 | 45,0 | 15,0 | 32,5 | 7,5 |
| | 3 | 40,0 | 12,5 | 27,5 | 6,3 |
| | 4 | 35,0 | 10,0 | 25,0 | 5,0 |
| Россия Кубогы | 1 | 40,0 | 15,0 | 27,5 | 7,5 |
| | 2 | 35,0 | 12,5 | 22,5 | 6,3 |
| | 3 | 30,0 | 10,0 | 20,0 | 5,0 |
| | 4 | 25,0 | 8,5 | - | 4,3 |
| Федераль округ чемпионаты | 1 | 25,0 | 7,5 | 22,5 | 3,8 |
| | 2 | 20,0 | 7,0 | 18,0 | 3,5 |
| Республика чемпионаты | 1 | 20,0 | 3,5 | 20,0 | 1,8 |
| Россия беренчелеге (яшьләр, үсмерләр) | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |
| | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| Бөтендөнья | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| универсиадасы | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| Дөнья, Европа беренчелеге | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Бөтендөнья яшүсмерләр уеннары | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Европа яшүсмерләр фестивале | 1 | 40,0 | 40,0 | 20,0 | 20,0 |
| | 2 | 35,0 | 35,0 | 17,5 | 17,5 |
| | 3 | 30,0 | 30,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| Яшүсмерләр, өлкән яшүсмерләр арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 22,5 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 2 | 20,0 | 12,5 | 12,5 | 12,5 |
| | 3 | 17,5 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 4 | 15,0 | 7,5 | 7,5 | 7,5 |
| Россия беренчелеге (өлкән егетләр) | 1 | 35,0 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| | 2 | 28,0 | 5,5 | 14,0 | 2,7 |
| | 3 | 20,0 | 5,0 | 10,0 | 2,5 |
| Россия яшьләре Спартакиадасының финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 32,5 | 7,0 | 27,5 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 - 6 | 25,0 | 6,0 | 20,0 | 3,0 |
| Россия укучылары Спартакиадасының финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 30,0 | 7,0 | 25,0 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 - 6 | 22,5 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының бердәм календарь планына кертелгән Бөтенроссия ярышлары | 1 | 15,0 | 5,0 | 7,5 | 2,5 |
| | 2 | 12,5 | 2,5 | 6,8 | 1,3 |
| | 3 | 10,0 | 2,0 | 5,0 | 0,8 |
| Идел буе федераль округы беренчелеге | 1 | 20,0 | 5,8 | 10,0 | 2,9 |
| | 2 | 17,5 | 5,3 | 9,0 | 2,7 |
| | 3 | 15,0 | 4,8 | 7,5 | 2,4 |
| Олимпия резервы дәүләт училищесына керү | - | 25,0 | 5,0 | - | - |

9. Тренерларга, адаптив физик культура буенча укытучы- тренерларга (шул исәптән өлкәннәр өчен), спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга акчалата түләү төп эш урыны буенча гына билгеләнә (адаптив спорт мәктәпләреннән тыш).

10. Бүлек ай саен, агымдагы елның 15 числосына кадәр, Министрлыкка Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акча бирү турында гариза бирә.

11. Акчалата түләү оешма җитәкчесе боерыгы нигезендә ай саен башкарыла.